## БӨЕК ҖИҢҮНЕҢ 75 ЕЛЛЫГЫНА БАГЫШЛАНГАН СӘХИФӘ

*2020 елда Бөек Ватан сугышында җиңүнең 75 еллыгы билгеләп үтеләчәк. Русия Президенты Владимир Путин указы белән ул "Хәтер һәм дан елы" дип игълан ителде.*

### Гаилә альбомын актарганда...

Гаилә альбомын карап утырганда, минем карашым таушалып беткән аклы-каралы фотографиягә төште. Күкрәге тулы орден-медальләр таккан өлкән яшьләрдәге бу бабайның кем булуы белән кызыксындым. Бабам миңа бу фотодагы кешенең үз әтисе, димәк, миңа картбабыкай тиешле кеше булуын әйтте.

Каһиров Габделхак Каһирович 1942 нче елда Бөек Ватан сугышына китә. Взвод командиры була. Аңың хатлары да сакланган. Ул аларда дошманның чигенүе, совет армиясенең зур җиңүләр белән алга баруы турында язган. Кызганычка каршы, бабабыз сугыш кырында ятып калган. Ленинградны фашистлардан азат иткәндә, ул батырларча вафат була.

Сугышка кадәр картбабам Башкортстанның Илеш районы Ябалак авылында яшәгән, “Искра” колхозын җитәкләгән. Авылдашлары аны бары тик яхшы яктан гына искә алалар.

Мин үз бабам белән горурланам, үзем дә илебезнең лаеклы гражданины булып үсәргә, Ватаныбызга хезмәт итәргә телим.

***Алинә Әюпова,***

***Мөслим гимназиясенең 7 нче б сыйныфы укучысы***